**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «10» августыннан № 315

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Аҗаган» яшүсмерләр клубы муниципаль бюджет учреждениесе» Уставына өстәмәләр кертү турында»**

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Аҗаган» яшүсмерләр клубы» муниципаль бюджет учреждениесе Уставын Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында карар бирәм:

1. 1 бүлеккә өстәмәләр кертергә: «Гомуми нигезләмәләр»:

1.5. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Аҗаган» яшүсмерләр клубы балаларны, яшүсмерләрне өстәмә белем, физик һәм рухи үсеш, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, сәламәтлек торышын яхшырту, елларын файдалы оештыруга юнәлдерелгән спорт секцияләрендә, техник спорт төрләре һәм сәнгать иҗаты түгәрәкләрендә системалы шөгыльләргә, патриотик тәрбия буенча балаларда һәм яшьләрдә ватанпәрвәрлек һәм Ватанга мәхәббәт тәрбияләүгә юнәлтелгән түгәрәкләргә җәлеп итү өчен төзелә. Әхлакый һәм патриотик тәрбия өлкәсендә дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү эшен камилләштерү»темасына семинар узды».

2. 2 бүлеккә «Яшүсмерләр клубы эшчәнлегенең максатлары һәм предметы»:

2.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: ««Ажаган» яшүсмерләр клубы башка юнәлешләрдәге: патриотик, спорт-техник, спорт, сәнгать-иҗади һәм савыктыру учреждениесе булып тора».

2.3. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Балаларны һәм яшүсмерләрне спорт секцияләрендә, патриотик тәрбия түгәрәкләрендә, спортның һәм сәнгатьнең техник төрләре буенча системалы дәресләргә җәлеп итү».

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**